| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.08.2019 г.Зеленодольск № 415

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 9 июлендә 314нче карары белән раслаган хезмәт вазыйфаларын башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксыну турында хәбәр итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан хәбәр итү тәртибенең 13 пунктында туры килмәүне бетерү, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында, Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 9 июлендә кабул ителгән 314 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу максатыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органы карамагындагы оешма (учреждение) җитәкчесе тарафыннан хәбәр итү тәртибенең 13нче пункты, вазыйфаи бурычларны үтәгәндә Зеленодольск муниципаль район Советының 2018 елның 9 июлендәге 314 номерлы карары белән расланган мәнфәгатьләр конфликтына китерә яки китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында Тәртипне яңа редакциядә бәян итәргә.:

2. «13. Комиссия хәбәрнамәләрне карый һәм Зеленодольск муниципаль район Советының 2018 елның 9 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча Комиссия турындагы нигезләмәне раслау турында» гы 313 номерлы

карары белән расланган комиссия турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны эш бирүчегә (яллаучы вәкиленә) җибәрә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хүокукый мәгълүмат рәсми сайтында (htpp:/pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1648017831 КПП 164801001
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ